**ШАЯН ТВ**

1) Әйдә, дустым, кушыл безнең җырга,
Үз илеңдә, үз телеңдә җырла.
Ал таңнары киләчәкнең – алда, -
Безнең буын гөрләп бара анда.

Кушымта:
Сәлам бирә яңа көннең күге,
ШАЯН ТВ сиңа юлдаш бүген.
Бергә чакта берни шомлы түгел,
Бердәм итә безне – ШАЯН ТВ.

2) Әйдә, дустым, кушыл безнең җырга,
Безнең җырны бөтен дөнья тыңлар.
Андый җырлар җирдә ятып калмас,
Киләчәккә очар безнең аваз.

3) Әйдә, дустым, кушыл безнең җырга,
Иң кирәкле сүзләр яңа җырда:
Аяз булсын күгең, Туган илем!
Яңгырасын мәңге Туган телем!